

Мордовиянен торле районнарында Боек Ватан сугышында һәлак булганнар һәйкәлләрен ремонтлау һәм жыю дәвам итә.
Татарларыбыз яшәгән авылларда да сугышта һәлак булганнарнын гына тvгел, ә тыл хезмәтчәннәренен, тыныч вакытта vлгән ветераннарнын исемнәре мәнгеләштерелгән урыннарны тәртипкә салалар.
Мәсәлән, Ләмберә районы ТатарТавла авылында, Темников районы Тархан авылында һәйкәл тирәсен жыештырып алалар. Кадошкино районы Латышовка авылындагы чистартылган, тәртипкә кертелгән Боек Ватан сугышында батырларча һәлак булганнар обелискына авыл мәктәбенен башлангыч сыйныф укучылары, житәкчеләре белән бергә, чәчәкләр салганнар. Латышовка мәктәбе укучылары 9 майга әзерлек вакытында vтә торган акцияләр, конкурсларда катнашалар. Фотода рәсемнәр конкурсы нәтижәләре дә кvренә.